| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА НОВОИГАЙКИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Иглай ав. **КАРАР**

«29» март 2024 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Некрасовка поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елның 10 апрелендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Некрасовка торак пунктында Дачная урамындагы 25 нче йорт янында элек раслангганнарга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 10 сәгать 00 минутка билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге составына керүче Некрасовка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 23.11.2023 ел, №3 карары;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Некрасовка торак пунктында гражданнар җыены карары 23.11.2023 ел, № 4.

2. Халык җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2024 елда Яңа Иглай авыл җирлегенең Некрасовка бистәсе территориясендә теркәлгән 1 гр инвалидлардан тыш., балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп:

- Некрасовка торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Некрасовка бистәсе территориясен төзекләндерү һәм тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу)».

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Яңа Иглай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Х. Ханәфиев